ГЛАВА
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский
район 422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст.
поселогы , Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.11.2021 № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегенең Борындык тимер юл станциясе поселогында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегенең 2019 елның 15 октябрендәге 74/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (2019 елның 15 декабрендәге 77/7 номерлы редакциясендә) карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегенең торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 3 декабренә 10.30 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: 422490, Татарстан Республикасы Чүпрәле районы, Борындык тимер юл станциясе поселогы, Вокзал ур., 27а.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге Борындык тимер юл станциясе поселогында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә рөхсәтегез бармы:

- Борындык тимер юл станциясе поселогында урамнарны яктыртуны ремонтлау;

- Борындык тимер юл станциясе поселогында зиратны карап тоту;

- Борындык тимер юл станциясе поселогында су җыю колонкаларын ремонтлау һәм төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»».

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегенең Борындык тимер юл станциясе поселогында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы В.Г. Ранцев